**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**РЫБНО-СЛОБОДСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.12.2022 Балык Бистәсе штп. №368пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 28.12.2020 №289пи карары белән расланган "2021-2025 елларга Балык Бистәсе муниципаль районының яшьләр сәясәтен үстерү" муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы яшьләр министрлыгының “Муниципаль программаларны актуальләштерү турында"гы 03.11.2022 №5507/исх-РС хаты нигезендә, муниципаль норматив хокукый актларны Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына туры китерү максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 28.12.2020 №292пи карары белән расланган «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының авыл яшьләре» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1) программа паспортын түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга:

| | |
|---|---|
| Программаны эшләү өчен нигезләмәләр | «Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында»30.12.2020 № 489-ФЗ Федераль закон; «Татарстан Республикасында яшьләр һәм дәүләт яшьләр сәясәте турында» 19.10.1993 ел, №1983-XII Татарстан Республикасы Законы; «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» Россия Федерациясе Президентының 04.02.2021 ел, №68 Указы; «Мәгариф» милли проектының «Социаль активлык», «Патриотик тәрбия» Федераль |

| | |
|---|---|
| | проектлары; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 17.03.2011 № 204 карары |

1.2) " Программа бурычлары» пунктын түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«- Яшьләрнең социаль үсеше белән идарә итү, аларның иҗади потенциалын республиканың конкурентлыкка сәләтен ныгытуда куллану, яшь буынның тормыш сыйфатын күтәрү өчен оптималь шартлар тудыру;

- Татарстан Республикасы яшьләренә патриотик тәрбия бирү системасын үстерү һәм модернизацияләү;

- дәүләт яшьләр сәясәтенең нәтиҗәлелеген арттыру;

- яшьләр сәясәте учреждениеләренең инфраструктурасын ныгыту һәм энергетик нәтиҗәлелеген арттыру.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын башкаручы Р.Л. Исланов